**МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.12.2021 Казан шәһәре № 352/2-пр

**Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 1 июлендәге 135/2-пр номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның 22 һәм 48 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 27 октябрендәге 346-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 1 июлендәге 135/2-пр номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Министрлыкның конкурс комиссиясе составына министр һәм (яисә) министр тарафыннан вәкаләтләр бирелгән граждан хезмәткәрләре (шул исәптән дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре бүлекчәсеннән һәм граждан хезмәтенең

вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздырыла торган бүлекчәдән), шулай ук әлеге Нигезләмәнең 2.4.1 пункты нигезләмәләре нигезендә Министрлыкның конкурс комиссиясе составына кертелүче бәйсез экспертлар – граждан хезмәткәрләренең тиешле һөнәри хезмәт өлкәләрендә һәм төрләрендә кадрлар технологияләре һәм граждан хезмәте мәсьәләләре буенча белгечләр буларак фәнни, мәгариф һәм оешмалар вәкилләре керә.

Конкурс комиссиясе составына әлеге пунктның беренче абзацында аталган затлар белән беррәттән Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет (алга таба - Иҗтимагый совет) вәкилләре кертелә. Әлеге вәкилләрнең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан кимендә дүрттән берен тәшкил итәргә тиеш.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.4.1 – 2.4.3 пунктлар өстәргә:

«2.4.1. Министрлыкның конкурс комиссиясе составына кертелә торган фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар вәкилләре Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре һәм кадрлар эшләре буенча департамент тарафыннан министр үтенече буенча чакырыла һәм сайлап алына, үтенеч бәйсез экспертларның персональ белешмәләре күрсәтелмичә җибәрелә. Министрлыкның конкурс комиссиясе составына кертелә торган Иҗтимагый совет вәкилләре Иҗтимагый совет карары белән билгеләнә.

2.4.2. Министрлыкның конкурс комиссиясендә бәйсез экспертның гомуми булу срогы өч елдан артык була алмый. Әлеге срок Министрлыкның конкурс комиссиясе составына бәйсез эксперт беренче мәртәбә кертелгән вакыттан исәпләнә. Әлеге бәйсез экспертны Министрлыкның конкурс комиссиясе составына кабат кертү Министрлыкның конкурс комиссиясендә булу срогы тәмамланганнан соң өч елдан да иртәрәк була алмый.

2.4.3. Министрлыкның конкурс һәм аттестация комиссияләрендә бәйсез экспертның гомуми булу срогы өч елдан артыграк була алмый.»;

2.8 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Конкурс комиссиясенең әгъзасы яисә кандидат тәкъдиме белән утырышны видеоконференция форматында (техник мөмкинлек булганда) үткәрү турында, сәбәбен (нигезләвен) күрсәтеп, Конкурс комиссиясе тарафыннан карар кабул ителергә мөмкин.»;

3.4 пунктның алтынчы һәм җиденче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«нотариаль яисә хезмәт (эш) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган хезмәт кенәгәсе күчермәсен һәм (яисә) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләрне һәм (яисә) гражданның хезмәт (эш) эшчәнлеген раслый торган башка документларны (хезмәт (эш) эшчәнлеге беренче мәртәбә башкарыла торган

очраклардан тыш);

белем һәм квалификация турындагы документларның күчермәләрен, шулай ук граждан теләге белән, өстәмә һөнәри белемен нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрүне яисә бирүне раслый торган документларның, фәнни дәрәҗә, фәнни исем бирү турында документларның күчермәләрен, алар нотариаль яисә хезмәт (эш) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган булырга тиеш;»;

4.12.1 пунктта таблицадан соң беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эшне бәяләгәндә кандидат 0дән 10га кадәр балл алырга мөмкин.»;

4.12.3 пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Индивидуаль әңгәмә узу нәтиҗәләре буенча кандидат 0дән 10га кадәр балл алырга мөмкин.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары – министр М.А. Җәббаров